| | |
|---|---|
| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***<br>***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ*** | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН***<br>***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ*** |

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

10 июль 2017 ел                                                                                    № 3-21

**«Буа муниципаль районы Буа шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында»**

Буа муниципаль районының Буа муниципаль районы архитектура бүлеге башлыгының Буа шәһәре Советының 2007 елның 09 августындагы 2-9 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районының Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышканнан соң, Буа муниципаль районы Буа шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясе бәяләмәсен һәм 2017 елның 10 июлендә уздырылган гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Буа шәһәр Советы карар кылды:

1. Буа муниципаль районының Буа шәһәрендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына, Ж-1 - индивидуаль торак йортлар белән төзелеш зонасыннан Д1- эшлекле, иҗтимагый һәм коммерциячел билгеләнештәге зонага үзгәртеп, Вахитов ур., 56 (кадастр номеры 16:14:990149:52) урнашкан территорияне зоналаштыру өлешендә үзгәрешләр кертергә (кушымта).
2. Әлеге карарның рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керүен билгеләргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Буа муниципаль районының Буа шәһәре
башлыгы урынбасары                                                                С.А. Зайцева

**КАРТА ГРАДОСТРОИТЕЛЬНОГО ЗОНИРОВАНИЯ ГОРОДА БУИНСКА. ВНЕСЕНИЕ ИЗМЕНЕНИЙ** **Приложение 1**

